# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2025 елның 11 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының протоколы төзелде:

«Сез, 2026 елда 1төркем инвалидларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 750 (җиде йөз илле) сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Заречная урамындагы 24нче йорттан алып - 34нче йортка; Лесная урамындагы 1А йортыннан алып – 7нче йортка кадәр юлга вак таш сатып алу, төяү, ташу, тарату);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 24 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 14.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен – 14, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип таныргa.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

«Сез, 2026 елда 1төркем инвалидларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 750 (җиде йөз илле) сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Заречная урамындагы 24нче йорттан алып - 34нче йортка; Лесная урамындагы 1А йортыннан алып – 7нче йортка кадәр юлга вак таш сатып алу, төяү, ташу, тарату);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Тархан авылы, Лесная ур., 2 йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тархан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тархан авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова